ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» апреля 2020 ел № 112

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» бүлмәләрен капиталь төзекләндерү буенча өлешчә ремонт эшләре башкару турында

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдиренең «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» бүлмәләрен, капиталь эшләр башкару чорына имин хезмәт шартлары булдыру максатларында белем бирү процессында тәрбияләнүчеләрнең һәм учреждение персоналының гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә туры килә торган хезмәт шартлары тудыру өчен, эш көне булмаган (ял) көннәрдә капиталь төзекләндерү буенча өлешчә ремонт эшләре башкару турында 2020 елның 26 мартындагы 17 номерлы (№1941исп 27.03.2020) үтенечнамәсе белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2013 елның 15 маендагы 26 номерлы карары белән расланган "Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш режимын урнаштыруга, тотуга һәм оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" СанПиН 2.4.1.3049-13 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрнең һәм нормативларның 17.11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында» 2020 елның 20 мартындагы 98 номерлы карары нигезендә, белем бирү процессына комачауламыйча һәм норматив таләпләрне бозмыйча, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау һәм аның янындагы территорияне эш көне булмаган (ял) көннәрдә төзекләндерү эшләрен башларга:

04.04.2020 дән 05.04.2020 гә кадәр;
11.04.2020 дән 12.04.2020 гә кадәр;
18.04.2020 дән 19.04.2020 гә кадәр;
25.04.2020 дән 26.04.2020 гә кадәр.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдиренә һәм «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына:

2.1. Балаларның мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бинасына капиталь ремонт ясау буенча ремонт эшләре алып бару территориясендә катнашуына юл куймый торган чараларны тәэмин итәргә.

2.2. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренә учреждениедә ремонт эшләре вакытында куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре белән таныштыру инструктажы үткәрергә.

2.3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бинасына капиталь ремонт ясау эшләре башлану турында ата-аналар игътибарына җиткерергә.

2.4. Норматив документлар таләпләренә туры китереп ремонт эшләрен башкарганда куркынычсызлык техникасын һәм янгын куркынычсызлыгын саклауны тәэмин итәргә.

2.5. Әлеге карарны гамәлгә ашыру буенча локаль норматив актлар эшләргә һәм кабул итәгә.

2.6. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бинасына капиталь ремонт буенча өлешчә ремонт эшләрен билгеләнгән вакытта башкаруны шәхси контрольгә алырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**